РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский
район, с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай
районы, Мәсгут авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«11» октябрь 2024 ел.** **№ 5**

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсәгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Мәсәгүт авыл җирлеге Уставының 15.1 ст., Азнакай муниципаль районының «Мәсәгүт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсәгүт авыл җирлегенең Яхшы-Бай торак пунктында, Урман урамы, 10 адресы буенча урнашкан, Яхшы-Бай торак пунктында сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2024 елның 25 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсъәләне түбәндәгечә расларга:

Сез, 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсәгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән, шулай ук 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы:

- Яхшы-Бай торак пунктында урнашкан җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрен) тезекләндерү (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якшы-Бай торак пунктындагы чишмәне төзекләндерү);

-Ремонт, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якшы-Бай торак пунктындагы зират коймасын алыштыру (демонтаж, монтаж, панельләр сатып алу)

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсәгут авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 14 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсәгут авыл җирлеге Башкарма комитетында Мәсәгут авылы, Дуслык ур., 12 адресы буенча урнашкан гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә;

- Мәсәгут торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмат материаллар әзерләргә;

- Мәсәгут торак пункты халкына гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Мәсәгүт авылы җирлегенең Яхшы-Бай торак пунктының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз кечене керә.

Башлык И.А.Вильданов